КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 820

Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда,

конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 5 пунктындагы өченче абзацыннан һәм 25 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин